КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018ел, 29 декабрь г.Казань № 1318

2018-2022 елларга Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 3 декабрь, 2446-б номерлы боерыгы белән расланган «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Иминлек Советының һәм Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссиянең 2018 елның 13 апрелендәге ПР-87 номерлы уртак утырышы беркетмәсенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2018-2022 елларга Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен (алга таба – Концепция) расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Концепцияне гамәлгә ашыру буенча системалы интегратор итеп – Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын;

функциональ заказчы итеп – Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгын.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларга яшәү мохитенең комплекслы иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл иткәндә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын гамәлгә кертү

эшчәнлеген гамәлгә ашырганда әлеге Концепциянең әлеге карары белән расланган нигезләмәләренә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны сакау идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин